Марсель Галиевнең иҗади мирасын өйрәнү, пропогандалау максатыннан

мәктәп укучылары һәм укытучылар арасында

I Республикакүләм Марсель Галиев укулары

НИГЕЗЛӘМӘСЕ

Марсель Галиев укулары күренекле якташ язучының иҗатын өйрәнү, пропагандалау, "2014-2020 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы"н тормышка ашыру максатыннан үткәрелә.

1. Укуларның максаты:

Укучыларны һәм укытучыларны фәнни-эзләнү эшләренә тарту;
Матур әдәбият аша туган телгә, милләткә карата хөрмәт тәрбияләү;
Гомуми урта белем бирү йортларында белем бирүче укытучыларны үстерү юлларын билгеләү, тәҗрибә уртаклашуга тарту.

2. Катнашучылар:

I Республикакүләм Марсель Галиев укуларында гомуми белем бирү учреждениеләренең 8-11 нче сыйныф укучылары, татар теле һәм әдәбияты укытучылары катнаша.

3. Марсель Галиев укуларын оештыручылар:

Казан федераль университеты Идел буе төбәкара мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерләү үзәге, Татарстан Республикасы язучылар Союзы, Азнакай муниципаль районының мәгариф бүлеге.

4. Үткәрү шартлары һәм тәртибе:

Укулар **2 турда** үткәрелә:

1 тур – 2014 елның 5 апреленә кадәр оештыру комитеты бәйгедә катнашу өчен гаризалар, фәнни эшләр, тезислар кабул итә. Гариза, тезис һәм фәнни эшне Ilgiza.Ilyasova@edu.tatar.ru адресына җибәрергә кирәк (Хәбәрләшү өчен тел.: 8(85592) 7-66-79, 89872137116 - Илгизә Миркасыймовна; 8(8342)33-75-98, 89093088105 – Сиринә Миннегалимовна).

2014 елның 5-17 апрелендә эшләр жюри тарафыннан тикшерелеп, иң яхшы эшләргә 2 нче турга чакыру җибәрелә. Эшләр жюри тарафыннан тикшерелә һәм бәяләнә, таләпләр туры килгән эшләрнең авторларына укуларда катнашу өчен чакыру "Азнакай шәһәре гимназиясе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе сайтына куела.

2 тур - 2014 елның 28 апрелендә укулар Татарстан Республикасы "Азнакай шәһәре гимназиясе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә үткәрелә.

Укытучы яки укучы үзе сайлаган темага чыгыш әзерли (эзләнү эше, мастер-класс, проект эше, конкрет методика белән эшкәртелгән практик яки эксперименталь материал булырга мөмкин). Эзләнү эшләренә түбәндәге юнәлешләр тәкъдим ителә:

1. М. Галиев – танылган әдип – шагыйрь, прозаик, публицист һәм драматург.
2. М. Галиев иҗатын мин ничек күзаллыйм.
3. М. Галиев иҗатында юмор һәм сатира. («Шаян истәлекләр», «Туган як мәзәкләре» — III томда; «Йотымлап-йотымлап елмаю» — VI томда).
4. М. Галиевнең драматургия, әдәби тәрҗемә һәм җыр текстлары иҗат итү өлкәләрендәге үзенчәлекле уңышлары.
5. М. Галиев иҗатында туган як темасы. (Шигырьләр — I, II том; проза — III– IV том).
6. М.Галиев иҗатында фәлсәфи уйланулар ("Догалы еллар" (V том); "Рух" әсәре (II том) буенча).

5. Оештыру взносы – 300 сум